| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 09.12.2020 | Казан ш. | № 374-172/кс-2020 |

«ТГК-16» акционерлык җәмгыяте өчен 2021-2025 елларга агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «ТГК-16» АҖ) өчен агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «ТГК-16» АҖ өчен агынты суларны транспортлауга 2021-2025 елларга озак сроклы җайга салу параметрларын билгеләргә.

4. Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «ТГК-16» акционерлык җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны

агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
09.12.2020 № 374-172/кс-2020 карарына
2 нче кушымта

Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «ТГК-16» АҖ өчен 2021-2025 елларга агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «ТГК-16» АҖ (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алынмыйча күрсәтелгән) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 6,51 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 6,74 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 6,74 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 6,85 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 6,85 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 7,09 |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 7,09 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 7,22 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 7,22 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 7,47 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
09.12.2020 № 374-172/кс-2020 карарына
2 нче кушымта

Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «ТГК-16» АЖ өчен 2021-2025 елларга агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| Т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «ТГК-16» АЖ | | | | | | |
| 1.1 | Агынты суларны транспортлау | 2021 | 552,40 | X | - | - | - |
| | | 2022 | X | 1 | - | - | - |
| | | 2023 | X | 1 | - | - | - |
| | | 2024 | X | 1 | - | - | - |
| | | 2025 | X | 1 | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге